МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** 07.12.2017

Казан шәһәре

**БОЕРЫК** 1478-п

**Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчә торган һәм җитештерү су белән тәэмин итү скважинасының санитар саклык зонасы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга 2012 елның 17 декабрендәге ТАТ 01926 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2012 елның 9 ноябрендәге №16.11.20.000.Т.001570.11.12 дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ тарафыннан тапшырылган, Татарстан Республикасы Казан шәһәренең «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчә торган һәм җитештерү суы белән тәэмин итә торган скважинаның санитар саклык зонасын оештыру проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчә торган һәм җитештерү су белән тәэмин итү скважинасының санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ су алу скважинасының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ су алу скважинасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар үткәрергә тәкъдим итәргә:

«Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ су алу корылмасында санитар саклык зонасының чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
07.12.2017 № 1478 боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә**
**«Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчә торган**
**һәм җитештерү су белән тәэмин итү скважинасының**
**санитар саклык зонасы чикләре**

Җир асты байлыклары участогы Казан шәһәренең Мәскәү районында, Идел елгасының сул як ярында урнашкан. Су алу җайланмасы «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ территориясендә урнашкан бер эксплуатация скважинасыннан тора.

Су алу скважинасының географик координатлары:

$55^0 51' 35,9''$ т.к.., $48^0 57' 0,9''$ к.о.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Су горизонтының яхшы саклануын исәпкә алып, «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ су алу корылмасының санитар саклау зонасының беренче поясы чиге гамәлдәге койма чикләрендә билгеләнә: скважина авызыннан 2,0 м ераклыкта (7х7 кв. $м^2$ шакмак рәвешендә).

Санитар саклык зонасының II поясы

«Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ скважинасының икенче санитар саклык зонасы поясы территориясе 107,67 метрлы радиуслы әйләндән гыйбарәт.

Санитар саклык зонасының III поясы

Су алу скважинасының өченче санитар саклык зонасы поясы чиге скважина тамагыннан 761,33 м радиус белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
07.12.2017 № 1478 боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчә торган һәм җитештерү су белән тәэмин итү скважинасының санитар саклык зонасы чикләрендә территориядән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

Генераль директор
«Казан тимер-бетон эшләнмәләр
 заводы» ҖЧҖ
Судаков А.Б.

# САНИТАР САКЛЫК ЗОНАСЫ ПРОЕКТЫ
## Татарстан Республикасының Казан шәһәрендәге «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ хуҗалык-эчәр һәм җитештерү суы белән тәэмин итү скважинасы

Казан, 2010 ел.

Эшләүче турында мәгълүмат

| | |
|---|---|
| Тулы исеме | «ЮНОНА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| Юридик адресы | ТР, Казан шәһәре,  Чистай ур., 5 |
| Почта адресы | ТР, Казан шәһәре,  Чистай ур., 5 |
| Салым түләүченең тәңгәллек номеры | 1657074836 |
| Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП) | 165801001 |
| Төп дәүләт теркәү номеры | 1081690019290 |
| ИСӘП-ХИСАП СЧЕТЫ | 40702810300070007913 |
| Корреспондент счеты | 30101810300000000770 |
| Банкның исеме | «Энергобанк» АКБ, Казан шәһәре |
| Банкның тәңгәллек коды | 049205770 |
| Телефон | 843 5625001 21 |
| e-mail | lmgmari@mail.ru |
| Директор | Левушкина Марина Геннадьевна |

# ЭЧТӘЛЕК

ЭЧТӘЛЕК........................................................................................................................2
КЕРЕШ...........................................................................................................................3
СУ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ЧЫГАНАГЫНЫҢ САНИТАР ТОРЫШЫНА БӘЯЛӘМӘ.................................................................................................................... 4
СУ СЫЙФАТЫНА АНАЛИЗ ....................................................................................8
ГИДРОГЕОЛОГИК МӘГЪЛҮМАТЛАР...........................................................................10
СУ КУЛЛАНУ. ТАШЛАНДЫК СУ АГЫЗУ. СКВАЖИНАНЫҢ ЭШ РЕЖИМЫ....................12
БЕРЕНЧЕ САНИТАР САКЛЫК ЗОНАСЫ ЧИКЛӘРЕН, ИКЕНЧЕ ҺӘМ ӨЧЕНЧЕ ПОЯС ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ.............................................................................................14
Санитар саклык зонасының 1 поясын исәпләү......................................................14
Санитар саклык зонасының 2 поясын исәпләү......................................................15
Санитар саклык зонасының 3 поясын исәпләү......................................................16
ТЕРРИТОРИЯЛӘРДӘН ХУҖАЛЫК ӨЧЕН ФАЙДАЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ РЕЖИМЫ ................................................................................................18
Беренче пояс буенча чаралар..................................................................................20
Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар...........................................................21
Җир асты байлыкларын саклауга контрольлек оештыруга карата таләпләр....................22
ТЕРМИННАР ҺӘМ БИЛГЕЛӘМӘЛӘР ..........................................................................25
ӘДӘБИЯТ .......................................................................................................................26

## КЕРЕШ

Проект нигезендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖнең хуҗалык-эчәр һәм җитештерү суы белән тәэмин итү скважинасының санитар саклык зонасын оештыру мөмкинлеге карала. Хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү скважинасы Казан шәһәренең «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ территориясендә урнашкан. Скважина хуҗалык-эчәргә яраклы һәм җитештерү ихтыяҗлары өчен кулланыла. Сайлана торган сулар саны хуҗалык-эчә торган һәм җитештерү максатлары өчен тәүлеккә 109,246 м$^3$ (елына 24,398 мең м$^3$) тәшкил итә.
Проектны эшләү СанПиН 2.1.4.1110-02 «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрнең санитар саклык зоналары» нигезендә башкарыла.

СанПиН 2.1.4.1110-02 «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрнең санитар саклык зоналары» су белән тәэмин итү һәм эчәргә яраклы су чыганакларын санитар саклау зоналарын оештыру һәм эксплуатацияләүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр билгели.

Санитар кагыйдәләрне үтәү гражданнар, шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар өчен мәҗбүри булып тора. Санитар саклык зоналары барлык суүткәргечләрдә дә, җир өстендәге һәм җир асты чыганакларыннан су бирүче ведомствога бәйсез рәвештә, оештырыла.

Санитар саклык зонасында режим булдыру һәм тәэмин итүнең төп максаты булып су белән тәэмин итү чыганакларын һәм суүткәргеч корылмаларын, шулай ук алар урнашкан территорияләрне санитар саклау тора. Санитар саклык зоналары өч пояс составында оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу җайланмалары, барлык су алу корылмалары һәм су үткәрү каналы урнашкан территорияне үз эченә ала. Аның максаты – су алу урынын һәм су алу корылмаларын очраклы яки аңлы рәвештә пычратудан һәм зарарланудан саклау. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

## СУ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ЧЫГАНАКЛАРЫНЫҢ САНИТАР ТОРЫШЫНА ХАРАКТЕРИСТИКА

Җир өслегенең абсолют билгеләре 100-110 м булган җир асты байлыклары участогы Казан шәһәренең Мәскәү районында Тэцевская урамында, Идел елгасының сул як ярында урнашкан. Скважина «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ территориясендә 420051, ТР, Казан шәһәре, Тэцевская ур., 295 адресы буенча урнашкан. Хәзерге скважина 2004 елдан бирле файдаланыла.

Бу территориянең геологик төзелешенең үзенчәлеге булып, палеодолина елгасының палеодолина елгасының плиоценада формалаштырылган катлаулы катламына тирән вакланган булуы тора.

Төче җир асты сулары бәйле геологик кисемнең өске өлешендә әлеге территориядә югары Пермьдәге казан ярусы һәм дүртенче чиреклек аллювиаль бераємлекләр катнаша. 60 м. га кадәр егәрлекле түбән Казан катламнары доломитлар, балчык, комташ, известьташ белән тәкъдим ителә. Түбәнге асъярусның терригенлы-карбонат берәмлекләренең эрозия өслегендә 35-46 м куәтле, нигездә,

төрле бөртекчәле комнар һәм балчык линзалары булган вакташ-чуерташ катнашкан комнар өелгән, акчагыль ярусының неоген системасы плиоцен катламнары ята. Югарыда 90 м кадәр куәтле аллювиаль комлы-балчыклы катламнарда туфраклы балчык, балчык, туфраклы ком, комнар ята, алар Идел елгасының дүртенчел тугай өсте террасасын китереп чыгара.

Гидрогеологик кисемнең өске өлешендә әлеге территориядә түбәндәге су кертү комплекслары бүлеп чыгарыла:

- су китерүче неоген-дүртенчел аллювиаль комплексы;
- су китерүче түбән Казан карбонат-терриген комплексы.

Өслектән беренче булып су йөртүчән неоген-дүртенчел аллювиаль комплексы урнашкан. Егәрлеге 25 м кадәр булган төре бөртекчәле комнар су үткәрүче токымнар булып тора. Пермь катламнарының эрозия өслегенә ятып, комплекс 10-120 м киңлектәге шактый үзгәрүчән егәрлек белән характерлана. Комплекс сулары аэрация зонасында туфраклы балчык һәм балчык катламнарының өске пычрануыннан сакланган. Статик дәрәҗәсе абсолют билгедә 53 м билгеләнә. Комплексның атмосфера явым-төшемнәре исәбенә мәйданы буенча таралган ачык, таркау өлеше бар. Аның су белән тәэмин ителеше тигез түгел, бу су сыйдыручы токымнарның куәтенең һәм литологик составының югары үзгәрүчәнлегенә бәйле. Җир асты суларын түбән катламнарга һәм Куйбышев сусаклагычына агызу юлы белән бушаталар.

Түбәндәрәк түбән Казан карбонат-терриген комплексы урнашкан.

Комплексның иң киң таралган токымнары - 10-15 м куәтле комташ, известьташ. Статистик дәрәҗәсе 51 м тирәнлегендә билгеләнә, бу 56 м абсолют билгесенә туры килә. Комплексны тукландыру түбән Казан утырмаларының көндезге өслеккә чыгу урыннарында атмосфера явым-төшемнәрен инфильтрацияләү хисабына башкарыла. Җир асты сулары түбән катламнарга һәм Куйбышев сусаклагычына агу юлы белән бушаналар.

Скважина «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖдә хуҗалык-эчәр һәм җитештерү суы белән тәэмин итү өчен кулланыла. Хуҗалык-эчәргә яраклы һәм җитештерү максатлары өчен сайлап алына торган сулар саны тәүлегенә 109,246 м$^3$ (елына 24,398 мең м$^3$) тәшкил итә, шуларның тәүлегенә 14,596 м$^3$ (елына 3,816 мең м$^3$) хуҗалык-эчәргә яраклы су ихтыяҗларына һәм тәүлегенә 94,65 м$^3$ (елына 20,582 мең м$^3$) предприятиенең җитештерү ихтыяҗларына тотыла.

Скважина урнашкан участок тимер капкалы койма белән әйләндереп алынган, участокта скважина бинасы урнашкан. 3х3 м үлчәмендәге бина кирпечтән, тимер ишекле. Скважина урнашкан кишәрлек үләнле һәм агач-куак үсемлекләре белән яшелләндерелгән. Скважина авызы кирпеч павильонда урнашкан.

Скважина 60 м тирәнлектә үзәктән кудыручы ЭЦВ 6-10-140 маркалы насос, шулай ук су пробаларын алу өчен кран белән җиһазландырылган.

Насос станциясе характеристикасы: скважинаның тирәнлеге – 100 м, ЭВЦ-6-10-110 насосының җитештерүчәнлеге — 10 м$^3$, насос басымы – 110 м. Скважина суның динамик дәрәҗәсен үлчәү өчен дәрәҗә үлчәгеч белән җиһазландырылмаган. Сайлап алына торган суның күләмен исәпкә алу СТВ-65 маркалы водомер кулланып алып барыла. Кулланыла торган суны исәпкә алу журналы алып барыла.

Скважина насосы белән суыртып алына торган су су манарасына, аннары «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ челтәренә тапшырыла.

Суэтем манарасы җитештерү һәм хуҗалык ихтыяҗларына бирү өчен даими су туплау һәм аны саклау өчен билгеләнгән. Су 6-10х140 ЭЦВ насосы ярдәмендә артезиан скважинасыннан су манарасына җибәрелә. Су манарасында даими су дәрәҗәсен саклау өчен ике очлык сүндергече (түбән һәм югары) бар. Югары датчик эшләп бетермәгән очракта, күчеш торбасы каралган. Манарадан су торбаүткәргеч буенча кулланучыларга бирелә. Манара фундаменты М150 бетонынннан 4000х400х1200 ныгытылган монолит рәвешендә башкарылган. Манара минераль мамык белән җылытылган СТ3 корычыннан ясалган һәм табаклы корыч белән тышланган: б = 1 мм, кыегы 300х150 б табагыннан = 16 мм әйләнәсе буйлап 12 данә күләмендә. Өстәмә рәвештә арматурадан растяжкалар, шулай ук су бирү һәм куллану өчен келәле арматура бар.

Төньяктан предприятие территориясе чигеннән 100 м ераклыкта ТЭЦ-3 территориясе урнашкан. Көнбатыштан предприятие 3 нче (Волгомост) Мостостровка отряды участогы белән чиктәш, аның территориясендә «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ чикләреннән 15 м ераклыкта отряд хезмәткәрләре өчен 1, 2 катлы торак йортлар урнашкан. Казан шәһәренең шәһәр төзелеше регламентлары буенча әлеге торак төзелеше объектлары белән шөгыльләнүче территория торак зонасы җирләре составына керми. Моннан тыш, җир кишәрлекләре бирелмәгән һәм гамәлдәге законнар нигезендә теркәлмәгән (Татарстан Республикасы буенча Күчемсез мөлкәт кадастры һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының теркәү палатасында белешмәләр юк). Сәнәгать мәйданчыгының көньяк ягында «Татгазторг» ҖЧҖ предприятиесе белән чиктәш, 65 м ераклыкта урман-парк зонасы бар, анда зур күләмле агачлардан һәм ялган агачлардан катнаш утыртылган. Сәнәгать мәйданчыгының көнчыгыш ягыннан «Агрострой» ҖЧҖ һәм «Торгмет» ЯАҖ белән чиктәш.

Скважинадан Тирән күлгә кадәрге ераклык 2,5 км тәшкил итә.

Скважина 1993 елда 110 метр тирәнлектә бораулаган, 96-110 метр тирәнлектә фильтр колоннасы бар.

Скважинаның факттагы конструкциясе 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Скважина конструкциясе

| Скважинаны бораулау елы | Скважинаның гомуми тирәнлеге, м | Насос маркасы | Скважинаның факттагы конструкциясе | | | фильтр конструкциясе | Сулы офыклар | Дебит, $м^3$/тәүлек |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | әһәмияте, | | | | |
| | | | | башлап | кадәр | | | |
| | 2 | | 4 | 5 | | 7 | 8 | 9 |
| 1993 | буенча | ЭЦВ 6-10-140 | 325 утырту колоннасы | 0 | 72 | 72 м озынлыгындагы 0325 утырту колоннасы. Челтәрсыман фильтр сальник һәм фильтрның өске өлешеннән тора, торбаларның диаметры 168 мм. Фильтрның эш өлеше 96 м дан 100 м га кадәр тирәнлектә урнаштырылган. Фильтр колоннасының гомуми озынлыгы 14 м, шул исәптән фильтр бүлеге 8 м, эш өлеше 6 м. | Су йөртә торган түбән Казан карбонат-терриген комплексы (P2kzl). Су белән тәэмин итүче һәм токымлы булып ярыклы известьташлар хезмәт итә | 109,2 |
| | | | 0219 эксплуатация колоннасы | | | | | |
| | | | фильтр колоннасы 0168 | | | | | |
| | | | фильтр өсте өлеше | | | | | |
| | | | фильтрлау өлеше | | | | | |

Су куллану һәм ташландык суларны агызу буенча баланс таблицасы.

| | Су кулланучылар исеме | Үлчәү берәмлеге | Су куллану нормасы | Су куллану | | Ташландык суларны агызу | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Кулланучылар хокукларын яклау | $м^3$ тәүлегенә | Су кулланучылар саны | $м^3$ |
| | 1. Җитештерү бүлекчәсенең хуҗалык-көнкүреш ихтыяҗлары | | | | | | |
| 1 | Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хуҗалык-көнкүреш ихтыяҗлары | Кеше. | 25 | 100 | 2,5 | 100 | 2,5 |
| 2 | 1 смена эшләгәндә эшчеләрнең душ ихтыяҗлары | данә | 500 | 14 | 7 | 14 | 7 |
| 3 | Ашханә | 1 төшке аш | 25 л | 100 | 2,5 | 100 | 2,5 |
| 4 | Транспорт чараларына салу һәм аларны карау | 1 бер. | 34 ел | 10 | 0,34 | 10 | 0,34 |
| 5 | Территориягә сибү | кв.м | 3 л | 752 | 2,256 | 752 | 2,256 |
| | Җәмгысе | | | 14,596 | 14,596 | 14,596 | 14,596 |
| | 2. Җитештерү секторы | | | | | | |
| 1 | Җыелма тимер-бетон | м.куб. | 120 л | 200 | 24 | 200 | 24 |
| 2 | Бетон эшләнмәләр | м.куб. | 110 л | 200 | 22 | 200 | 22 |
| 3. | Товар бетоны | м.куб. | 250 л | 194,6 | 48,65 | 194,6 | 48,65 |
| | Җәмгысе: | | | 94,65 | 94,65 | 94,65 | 94,65 |
| | Барлыгы: | | | 109,246 | 109,246 | 109,246 | 109,246 |

# СУНЫҢ СЫЙФАТЫНА АНАЛИЗ

Суның сыйфатына контроль «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе тарафыннан алып барыла. Җир асты сулары сыйфатының гигиеник критерийлары булып тора:

- рөхсәт ителгән концентрацияләр (ПДК) һәм химик матдәләрнең рөхсәт ителгән чик дәрәҗәләре (ОДУ);
- санитар-күрсәтмә микроорганизмнарның рөхсәт ителгән микъдары; органолептик үзлекләре;
- радиацион куркынычсызлыкны тәэмин итүче нормативлар.

30.11.2010 ел, № 39476 беркетмә нигезендә, тикшерелгән күрсәткечләр буенча су пробасы СанПиН 2.1.4.1074-01 таләпләренә җавап бирми, калган тикшерелгән күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 таләпләренә җавап бирә.

Скважинаның су пробаларын тикшерү нәтиҗәләре 2 нче таблицада китерелгән. 30.11.2010 елдагы 39476 номерлы лаборатория сынаулары беркетмәсе кушымтада.

2 нче таблица

| Билгеләнә торган күрсәткечләр | Үлч. берәмлеге | Рөхсәт ителгән дәрәҗәнең зурлыгы, иң күбе | Тикшеренүләр нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Исе | баллар | 2 | <2 |
| Тәме | баллар | 2 | <2 |
| Төслелеге | сы | 20 | <5 |
| Тоныклыгы | мг/л | 1 5 | <0,58 |
| Водород күрсәткече | | 6,0-9,0 | 7,8 |
| Тимер | мг/л | 0,3 | 0,1 |
| Гомуми минерализация (коры калдык) | мг/л | 1 000 | 532 |
| Гомуми катылыгы | мг-экв/л | 7 | 8,3 |
| Нефть продуктлары | мг/л | 0,1 | 0,009 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Перманганат окисе | мгО2/л | 5 | 1,6 |
| селтелелеге | мг-экв/л | - | 6 |
| Фенол | мг/л | 0,001 | <0,0005 |
| Азот буенча аммиак | мг/л | 2 | <0,05 |
| Нитритлар | мг/л | 3 | <0,003 |
| Нитратлар | мг/л | 45 | 3,5 |
| Сульфатлар | мг/л | 500 | 26,8 |
| Фторидлар | мг/л | 1,5 | 0,17 |
| Хлоридлар | мг/л | 350 | 56 |
| Полифосфатлар | мг/л | 3,5 | 0,54 |
| Марганец | мг/л | 0,1 | <0,001 |
| Молибден | мг/л | 0,25 | 0,0025 |
| Мышьяк | мг/л | 0,05 | <0,005 |
| Никель | мг/л | 0,1 | <0,005 |
| Бор | мг/л | 0,5 | <0,05 |
| Хром | мг/л | 0,05 | <0,005 |
| Селен | мг/л | 0,01 | <0,0001 |
| Кальций | мг/л | - | 120,2 |
| Цианидлар | мг/л | 0,035 | <0,01 |
| Бакыр | мг/л | 1 | 0,015 |
| Кадмий | мг/л | 0,001 | 0,0003 |
| Цинк | мг/л | 5 | 0,01 |
| Кургаш | мг/л | 0,03 | 0,0003 |
| Гомуми микроб саны | КОЕ/мл | 50 | ачыкланмаган |
| Гомуми колиформ бактерияләр | КОЕ/мл | рөхсәт ителми | ачыкланмаган |
| Термотолерантлы колиформ бактерияләр | КОЕ/мл | рөхсәт ителми | ачыкланмаган |
| а-радиоактивлык | Бк/л | 0,1 | 0,02 |
| в-радиоактивлык | Бк/л | 1 | 0,1 |

## ГИДРОГЕОЛОГИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

Җир өслегенең абсолют билгеләре 100-110 м булган җир асты байлыклары участогы Казан шәһәренең Мәскәү районында Тэцевская урамында, Идел елгасының сул як ярында урнашкан. Скважина «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ территориясендә урнашкан.

Бу территориянең геологик төзелешенең үзенчәлеге – ул Идел елгасының Пермь палеоүзәненең катлы катламына тирән итеп уелган, ул плиоценда формалашкан.

Төче җир асты сулары бәйле геологик кисемнең өске өлешендә әлеге территориядә югары Пермьдәге казан ярусы һәм дүртенче чиреклек аллювиаль берәмлекләр катнаша. Түбән Казан катламнары минус 6 м түбән ятучы 60 м кадәр егәрлеге булган доломитлар, балчыклар, комташлар, известьташлардан гыйбарәт. Түбәнге асъярусның терригенлы-карбонат берәмлекләренең эрозия өслегендә 35-46 м куәтле, нигездә, төрле бөртекчәле комнар һәм балчык линзалары булган вакташ-чуерташ катнашкан комнар өелгән, акчагыль ярусының неоген системасы плиоцен катламнары ята. Югарыда 90 м кадәр куәтле аллювиаль комлы-балчыклы

катламнарда туфраклы балчык, балчык, туфраклы ком, комнар ята, алар Идел елгасының дүртенчел тугай өсте террасасын китереп чыгара.

Гидрогеологик кисемнең өске өлешендә әлеге территориядә түбәндәге

су кертү комплекслары бүлеп чыгарыла:

- су китерүче неоген-дүртенчел аллювиаль комплексы;

- су китерүче түбән Казан карбонат-терриген комплексы. Өслектән беренче булып су йөртүчән неоген-дүртенчел аллювиаль комплексы урнашкан. Егәрлеге 25 м кадәр булган төре бөртекчәле комнар су үткәрүче токымнар булып тора. Пермь катламнарының эрозия өслегенә ятып, комплекс 10-120 м киңлектәге шактый үзгәрүчән егәрлек белән характерлана. Комплекс сулары аэрация зонасында туфраклы балчык һәм балчык катламнарының өске пычрануыннан сакланган. Статик дәрәҗәсе абсолют билгедә 53 м билгеләнә. Комплексның атмосфера явым-төшемнәре исәбенә мәйданы буенча таралган ачык, таркау өлеше бар. Аның су белән тәэмин ителеше тигез түгел, бу су сыйдыручы токымнарның куәтенең һәм литологик составының югары үзгәрүчәнлегенә бәйле. Җир асты суларын түбән катламнарга һәм Куйбышев сусаклагычына агызу юлы белән бушаталар.

Скважина «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖдә хуҗалык-эчәр һәм җитештерү суы белән тәэмин итү өчен кулланыла. Хуҗалык-эчәргә яраклы һәм җитештерү максатлары өчен сайлап алына торган сулар саны тәүлегенә 109,246 м$^3$ (елына 24,398 мең м$^3$) тәшкил итә, шуларның тәүлегенә 14,596 м$^3$ (елына 3,816 мең м$^3$) хуҗалык-эчәргә яраклы су ихтыяҗларына һәм тәүлегенә 94,65 м$^3$ (елына 20,582 мең м$^3$) предприятиенең җитештерү ихтыяҗларына тотыла.

## СУ КУЛЛАНУ, ТАШЛАНДЫК СУ АГЫЗУ, СКВАЖИНАНЫҢ ЭШ РЕЖИМЫ

«Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖ милкендә Казан шәһәре, ТЭЦ ур., 295 адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы 3,729 га булган җир кишәрлеге бар.

Предприятие территориясендә түбәндәге биналар һәм корылмалар урнашкан: җитештерү корпусы, административ бина, әзер продукция склады (тимер-бетон эшләнмәләре), тутыручылар складлы (инерт материаллары), компрессор, градирня, цемент складлы, БСУ, галерея, гараж, склад һәм көнкүреш бүлмәләре.

Предприятиенең гомуми мәйданы 3,729 га тәшкил итә, шуның 2,152 га – бетон өслеге. Предприятиенең эш режимы 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр. Предприятиедә 118 кеше эшли, эш сменалап башкарыла. Сменаларның максималь саны – 2.

Җитештерү куәте – елына 57500 м$^3$.

Су алу җайланмасы елына 365 көн автоматик режимда эшли. Су 503м$^3$ күләмендәге су манарасына бирелә, аннары предприятиенең суүткәргеч челтәренә тапшырыла.

Скважина «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖдә хуҗалык-эчәр һәм җитештерү суы белән тәэмин итү өчен һәм янгынга каршы кулланыла. Хуҗалык-эчәргә яраклы һәм җитештерү максатлары өчен сайлап алына торган сулар саны тәүлегенә 109,246 м$^3$ (елына 24,398 мең м$^3$) тәшкил итә, шуларның тәүлегенә 14,596 м$^3$ (елына 3,816 мең м$^3$) хуҗалык-эчәргә яраклы су ихтыяҗларына һәм

тәүлегенә 94,65 м$^3$ (елына 20,582 мең м$^3$) предприятиенең җитештерү ихтыяҗларына тотыла. Башка объектларны су белән тәэмин итү каралмаган, ягъни абонентлар юк. Шәһәр суүткәргеченнән су алынмый.

Предприятиенең җитештерү һәм хуҗалык-көнкүреш ташландык суларын агызу күләме тәүлегенә 109,246 м$^3$ (елына 24,398 мең м$^3$), шулардан тәүлегенә 14,596 м$^3$ (елына 3,816 мең м$^3$) хуҗалык-эчә торган ихтыяҗларга һәм тәүлегенә 94,65 м$^3$ (елына 20,582 мең м$^3$) агынты суларны кабул итү шартнамәсе нигезендә шәһәр канализациясенә агызыла. Предприятие суларын санитар-техник приборлардан шәһәр канализациясенә агызалар.

Предприятиенең канализация челтәрләре артезиан скважинасының санитар саклык зонасының беренче поясы кисми. Мостоотряд-3 урамындагы торак йортларны үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү шәһәр канализациясенә башкарыла. «Казан тимер-бетон эшләнмәләр заводы» ҖЧҖнең Мостоотряд-3 урамындагы торак йортлардан ташландык су агызуга катнашы юк.

## БЕРЕНЧЕ, ИКЕНЧЕ, ӨЧЕНЧЕ САНИТАР САКЛЫК ЗОНАЛАРЫ ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ

